# Тормыш юлы буйлап 65 ел бергә

**Тормышта яшәү – басу аша үтү түгел... Акыл ияләренең бу сүзләре яшьләрне гомер юлының катлаулы булуы турында искәртә. Гаилә кору җитди сынау булып тора. Янәшәсендә яшәүчеләрне тыңлый һәм ишетә белгән кешеләр парлы тормышта бәхеткә ия. Сезне менә шундый бер гаилә белән дә таныштырасы килә.**





Мәхәббәт һәм татулыкта озак еллар яшәп, үзара ихтирамны саклап кала алган гаилә парлары хөрмәт һәм соклану хисләре уята. Безнең районыбызда бер-берсенә һәм балалар тәрбияләүгә игътибар белән караган тату гаиләләр булуы куандыра. Морки районы Әлмәмәт авылында гомер кичерүче ирле-хатынлы Хәкимовлар күпләр өчен чын үрнәк булып торалар. Алар инде 65 ел гаилә булып гомер итәләр.

Билгеле, "Тимер туйны" бик сирәк кенә гаилә пары бәйрәм итә ала, шуңа күрә мондый юбилейны аз очрый торган дип әйтеп була. Бу юбилей иң нык материал – тимер исемен алган, ул каты гына түгел, тормышта иң кирәкле дә. "Тимер юбилей" – ир белән хатын арасындагы мөнәсәбәтләрнең таркалмый торган булуы, бу бәйләнешне сынаулар да, вакыт та өзә алмавы турында искәртмә ул. Мәкерле вакыт ташны да ватып ташларга сәләтле, ләкин мондый дата белән сыналган хисләрне сындырырга мөмкин түгел.

Мәсхүт белән Гөлира Хәкимовлар икесе дә Әлмәмәт авылында, гади крестьян гаиләсендә туып-үскәннәр. Сигезенче сыйныфка кадәр икесе дә Нурумбал мәктәбендә белем алалар. Гөлира Мостафа кызы укуын Морки бистәсе мәктәбендә дәвам итә (өч ел) һәм сәүдә-кооператив техникумына керә. Сатучы дипломы алып, Моркиның кулланучылар берләшмәсендә эшли. Мәсхүт Сафиулла улы шоферга укып чыга һәм бу һөнәренә бөтен гомере буена тугры булып кала: башта "Моркинский" совхозында машина йөртүче булып хезмәт итә, аннан соң, лаеклы ялга чыкканчы, Моркиның төзелеш оешмасында көч куя.

Ирле-хатынлы Хәкимовлар – хезмәт сөючән кешеләр, алар һәрвакытта да производство алдынгылары, социалистик ярыш җиңүчеләре булалар, күп кенә бүләкләр һәм грамоталарга лаеклар, икесе дә мактаулы "Хезмәт ветераны" исемен йөртәләр. Гаилә тормышының беренче елларыннан ук авыр вакытларда алар бер-берсенә ярдәмләшеп, иң якын кешесенең ышанычлы иңнәрен тоеп яшиләр. Күрәсең, гаиләдә очраган авырлыкларны һәм бәла-казаларны җиңеп чыгу аларны якынайткан, үзара мөнәсәбәтләрен ныгыткан. Бу парның тормыш юлы чәчәкләр белән түшәлмәгән, шулай да, бернинди кыенлыкларга карамастан, алар бер-берсенә карата җылы хисләрен, ихтирамны һәм тугрылыкны саклап кала алганнар, дүрт кызга – Земфира, Хәтирә, Эльвира һәм Альмирага гомер бүләк иткәннәр. Мин ирле-хатынлы Хәкимовлардан үзләренең гаиләләре турында сөйләүләрен үтендем.

- Сөйләрлек әллә нәрсә юк та инде, - диделәр алар бертавыштан. – Барысы да башкаларныкы кебек. Төрле хәлләр булды. Менә шулай итеп яшибез инде.

"Тимер пар" аз сүзле булып чыкты. Бәлки, алар хаклыдыр. Ул вакытларда күбесе шулай гади яшәгән, аерым сөйләрлек әйберләр булмаган да. Ул буын кешеләре бөтен гомерләре буенча бертуктамый эшләгәннәр. Хәкимовлар гаиләсе дә нәкъ менә шул хезмәт сөючән буынга карый.

- Безнең әти-әниебездән сабырлыкка һәм эшчәнлеккә өйрәнергә кирәк, - ди кызлары Альмира. – Аларның бердәмлеге – яшь гаиләләр өчен яхшы үрнәк.

Чыннан да, яшьләргә бергәләшеп яшәүнең серләренә өйрәнү, безнең каһарманнарыбызның киңәшләрен куллану һәм озак елларга гаилә тынычлыгын ничек саклап калуны аңлау комачауламас иде. Хәкимовларның күпьеллык гаилә тормышы серләре бик гади һәм һәркемгә аңлаешлы: үзара ярдәмләшеп яшәү, бер-береңнең хәленә керә белү, ихтирамлы мөнәсәбәт, кичерә белү һәм якын кешеңә ачу сакламау. Алар тормышны яраталар, һәр яңа көнгә сөенеп яшиләр. Алтмыш биш ел буе гаилә учагын кадерләп саклыйлар. Алга таба да аларның йортларында тынычлык һәм татулык хөкем сөрсен.

**АЛСУ НӘБИУЛЛИНА,**
**Әлмәмәт авылы китапханәсе мөдире.**
**Морки районы.**